**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.03.2019 г.Казань № 80

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертү) бәйге турында Нигезләмәне раслау турында

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте турында» федераль законы, 2005 елның 1 февралендә кул куелган 112 номерлы«Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә бәйге турында» Россия Федерациясе Президенты указы, 2018 елның 31 мартында кабул ителгән 397 номерлы «Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә бәйле бәйге үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 2003 елның 16 гыйнварендә кабул ителгән 3-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы, 2011 елның 14 мартында чыгарылган УП-127 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы турында Нигезләмәне раслау турында» һәм 2015 елның 11 декабреннән УП-1192 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест үткәрне оештыру мәсьәләләре» Татарстан Республикасы

Президенты Указлары, шулай ук 2018 елның 22 июнендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы үзгәртү турында» УП-454 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә

**боерам:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти граждандлык хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге турында тәкъдим ителгән Нигезләмәне расларга;

2. Әлеге боерык үз көченә рәсми рәвештә басылып чыккан көннән керә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз артымда калдырам.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы Спорт
министрлыгының 19.03.2019
кул куелган 80 номерлы карары
белән раслана

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә
(кадрлар резервына кертү) бәйге турында
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге тәртибе һәм шартлары билгеләнә. Гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге (алга таба – бәйге) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә бердәй мөмкинлек бирә торган конституцион хокукны, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) бәйге нигезендә вазыйфаи яктан үсүгә булган хокукын тәэмин итә.

1.1. Бәйге Министрлыкта 2004 елның 27 июлендә кул куелган 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында» федераль законының (алга таба – Федераль закон) 22 маддәсе, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендә кул куелган 112 номерлы «Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте вакант урынын биләүгә бәйге турында» Указы, 2018 елның 31 мартында кабу ителгән 397 номерлы «Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакант урыннарын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә бәйге үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 2003 елның 16 гыйнварендә кабул ителгән 3-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында дәүләти гражданлык хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы, 2011 елның 14 мартында кул куелган УП-127 номерлы «Татарстан Республикасында дәүләти гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы турында Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Президенты Указы, 2015 елның 11 декабрендә кул куелган УП-1192

номерлы «Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест үткәрүне оештыру мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә үткәрелә.

2. Бәйге Министрлыкта Татарстан Республикасы спорт министры (алга таба – министр) карары белән 2004 елның 27 июлендә кабул ителгән «Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 79-ФЗ федераль законы) һәм 2003 елның 16 гыйнварендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында дәүләти гражданлык хезмәте турында» 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 3-ЗРТ) буенча гражданлык хезмәтен биләүчене билгеләү бәйге нигезендә башкарыла торган вакант урын булган очракта үткәрелә.

2.1. Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә бәйге кадрлар һәм дәүләти хезмәт мәсьәләләре буенча сектор тарафыннан Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакант урыннарын биләүгә белгечләргә ихтыяҗ чыгу ихтималын һәм Министрлыкта гамәлдә булган кадрлар резервын бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

2.2. Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә бәйге Министрлыкта төзелгән бәйге комиссиясе тарафыннан әлеге Бәяләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

3. Бәйге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 маддәсе нигезендә түбәндәге очракларда үткәрелми:

а) Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасының (алга таба – гражданлык хезмәте вазыйфасы) «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләре вәкаләтләрен билгеле бер вакытка башкаруга билгеләгән чакта;

б) билгеле бер вакытка исәпләнгән вакытлы хезмәт контракты төзегән очракта;

в) гражданлык хезмәткәрен гражданлык хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә; 79-ФЗ федераль законның 28 маддәсенең 2 өлеше, 31 маддәнең 1

өлеше һәм 60.1 маддәсенең 9 өлешендә каралган очракларда;

г) гражданлык хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән дәүләт хезмәткәрен (гражданны) гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгән чакта.

4. Бәйге түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

а) вазыйфаи йөкләмәләрне Министрлык карары белән расланган вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүмат кулланып үтәү гражданлык хезмәтенең аерым вазыйфасына билгеләгән чакта;

б) министр карары белән гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә кергән гражданлык хезмәте вазыйфаларына билгеләгән чакта.

5. Бәйгедә 18 яшен тутырган Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән һәм гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен куелган дәүләт гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләп куелган квалификация таләпләренә җавап бирүче Россия Федерациясе гражданы катнашырга хокуклы.

Гражданлык хезмәткәре, бәйге үткәргән чорда нинди вазыйфа биләвенә карамастан, гомуми шартларда бәйгедә катнашырга хокуклы.

6. Бәйге ике этапта уза. Беренче этапта Министрлык һәм «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмати системасы» дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) мәгълүмати сайтларында бәйгедә катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан, шулай ук бәйге турында түбәндәге мәгълүмат: гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасы турында мәгълүмат, әлеге вазыйфаны биләр өчен кирәк булган квалификацион таләпләр, гражданлык хезмәтен узу шартлары, әлеге Нигезләмәнең 7 пункты нигезендә тәкъдим ителергә тиешле документларны кабул итү шартлары, урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итүнең соңгы чик вакыты, бәйгене үткәрүнең фараз ителгән вакыты, урыны һәм үткәрү тәртибе,

башка төрле мәгълүмат урнаштырыла. Бәйгедә катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан һәм бәйге турында мәгълүмат шулай ук басма вакытлы матбугатта да басылып чыгарга мөмкин.

7. Бәйгедә катнашырга теләгән Россия Федерациясе гражданы түбәндәге документларны тәкъдим итәргә тиеш:

а) шәхси гариза;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган фотолы анкета;

в) паспорт яисә аны алмаштыра торган копиясен (тиешле документ шәхсән бәйгегә килгәч күрсәтелә);

г) кирәкле һөнәри белем, квалификация һәм хезмәт стажын раслый торган документлар:

нотариаль рәвештә яки эш урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе (хезмәт эшчәнлеге (эш) беренче мәртәбә башкарылган очрактан тыш) күчермәсе һәм гражданның хезмәт эшчәнлеген (эшләүне) раслый торган башка документлар;

нотариаль рәвештә яки эш урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган белем һәм квалификацияне раслый торган документлар, шулай ук граждан теләге буенча өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрү яисә бирүне раслый торган документлар, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирүне раслый торган документлар күчермәсе;

д) гражданда гражданлык хезмәтенә керергә яисә аны дәвам итәргә комачаулый торган авыру юклыгын раслый торган документ;

е) 79-ФЗ федераль законы, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының башка указлары һәм Россия Федерациясе карарлары тарафыннан каралган башка документлар.

8. Дәүләт органында гражданлык хезмәте вазыйфасын биләгән бәйгедә катнашырга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре министр исеменә гариза бирә.

Башка дәүләт органында үткәрелә торган бәйгедә катнашырга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре әлеге дәүләт органының эш бирүчесе исеменә язылган анкета һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча фотосурәт белән бергә тутырылган, имзаланган һәм үзе гражданлык хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан расланган анкетаны тапшыра.

8.1. Әлеге Нигезләмәнең 7 һәм 8 пунктларында күрсәтелгән документлар Министрлык һәм «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмати системасы» дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмати системасының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге мәгълүмати сайтларында аларны кабул итү турында игълан урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көн дәвамында граждан (гражданлык хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша юллау ысулы белән яисә күрсәтелгән мәгълүмати системаны кулланып электрон формада Министрлыкка тәкъдим ителә.

Документларны электрон рәвештә тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Документларны вакытында тапшырмау, нигезле сәбәпсез аларны тулы булмаган күләмдә яисә беркетү кагыйдәләрен бозып тәкъдим итү гражданнан (гражданлык хезмәткәреннән) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Документларны вакытында тапшырмаган, нигезле сәбәп буенча аларны тулы булмаган күләмдә яисә беркетү кагыйдәләрен бозып тәкъдим иткән очракта министр документларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.

9. Граждан (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва кылган граждан (гражданлык хезмәткәре)

ризалыгы белән дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка сер кергән мәгълүматларга, вазыйфаи йөкләмәләрне башкару андый мәгълүматларны куллану белән бәйле булган очракта, керү рөхсәтен рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә.

Граждан тарафыннан министрлыкка тәкъдим ителгән мәгълүматларның дөреслеге тикшерелә. Электрон рәвештә тәкъдим ителгән мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә автомат рәвештә тикшерелә.

Гражданлык хезмәткәре тарафыннан тәкъдим ителгән мәгълүматларның дөреслеген тикшерү бары тик ул гражданлык хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә керә торган гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә үткәрелә торган бәйгедә катнашкан очракта гына тормышка ашырыла.

10. Граждан (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләү өчен куелган квалификация таләпләренә туры килмәгән очракта, шулай ук Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында законнары тарафыннан гражданлык хезмәтенә керү һәм узу өчен куелган чикләргә бәйле рәвештә бәйгедә катнашуга кертелми.

11. Бәйгенең икенче этабын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында карар министр тарафыннан гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә дәгъва итүчеләр тарафыннан бирелгән белешмәләрнең дөреслеген, шулай ук дәүләт һәм закон тарафыннан саклана торган башка сер кергән белешмәләрне тәкъдим иткәннән соң кабул ителә. Бәйгенең икенче этабы бәйгедә катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча уздырыла, ә дәүләт һәм башка закон белән саклана торган сер кергән мәгълүматларга рөхсәт рәсмиләштергән очракта, бәйгенең икенче этабын үткәрү вакыты эшкә алучы вәкиле тарафыннан билгеләнә.

Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары нигезендә тикшерү барышында гражданның гражданлык хезмәтенә керүенә

комачаулый торган хәлләр ачыкланган очракта, аңа министр тарафыннан бәйгедә катнашудан баш тарту сәбәпләре турында язма формада хәбәр җиткерелә. Әгәр граждан бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырса, бәйгедә катнашудан баш тарту сәбәпләре турында хәбәр аңа рәвешендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмати системасын кулланып көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ җибәрелә.

12. Бәйгедә катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә дәгъва кылучы әлеге карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

13. Министрлык бәйгенең икенче этабы башланганчы 15 календарь көннән дә соңга калмыйча үзенең рәсми сайтында һәм «Интернет» челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, бәйгедә катнашуга кертелгән гражданнар (гражданлык хезмәткәрләре) исемлеген (алга таба – кандидатлар) урнаштыра һәм кандидатларга тиешле хәбәрләрне язмача, шул ук вакытта бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга – күрсәтелгән мәгълүмати системаны кулланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ формасында җибәрә.

Бәйге уздырганда кандидатларга Россия Федерациясе Конституциясе һәм федераль законнар нигезендә хокукларның тигезлеге гарантияләнә.

14. Әгәр бәйге үткәрү нәтиҗәсендә гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, министр кабат бәйге үткәрү турында Карар кабул итә ала.

15. Бәйгене үткәрү өчен Министрлык боерыгы белән даими нигездә эшли торган бәйге комиссиясе төзелә. Бәйге комиссиясе составы, аның эш вакыты һәм тәртибе, шулай ук бәйге үткәрү методикасы Министрлык боерыгы белән билгеләнә.

16. Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яисә) вәкаләтле гражданлык хезмәткәрләре (шул исәптән кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре секторыннан, юридик һәм мобилизация эше секторыннан һәм гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге үткәрелә торган структур бүлекчәдән, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, шулай ук министр запросы буенча чакырылган гражданлык хезмәте белән бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез экспертлар – белгечләр сыйфатында фәнни, белем бирү һәм башка оешмалар вәкилләре керә. Бәйсез экспертларның гомуми саны бәйге комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлеше була.

Бәйге комиссиясе составына әлеге пунктның беренче абзацында аталган затлар белән беррәттән министрлык каршында оештырылган Иҗтимагый совет вәкилләре дә кертелә. Әлеге вәкилләр һәм бәйсез экспертларның гомуми саны бәйге комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән бер өлеше булырга тиеш.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары бәйге комиссиясе составына кертү өчен министр соравы буенча әлеге Совет тарафыннан тәкъдим ителә.

Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә дәүләт сере кергән белешмәләрне файдалануга бәйле гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә бәйге үткәрү өчен бәйге комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

Бәйге комиссиясе составы бәйге комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карарларга йогынты ясый алырга мөмкин булган мәнфәгатьләр каршылыклары барлыкка килү мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп төзелә,.

17. Бәйге комиссиясе комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

18. Бәйге гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның бу вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

Бәйге комиссиясе бәйге уздырганда кандидатларны тапшырылган белеме, гражданлык яисә башка дәүләт хезмәте узу, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы документлары нигезендә, шулай ук федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын кулланып, шул исәптән шәхси әңгәмә, анкета үткәрү, төркемләп дискуссияләр үткәрү, реферат язу яисә кандидатларның вакант гражданлык хезмәте урынын биләүгә бәйле мәсьәләләр буенча тест үткәрүне дә кертеп, бәйге процедуралары буенча бәяли.

Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатын бәялəгәндә бәйге комиссиясе гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләү өчен тиешле квалификация таләпләреннән һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук дәүләт гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

19. Бәйге комиссиясе утырышы кимендә ике кандидат булганда үткәрелә. Бәйге комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы дип санала. Бәйге комиссиясе утырышын бары тик аның гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми. Бәйге комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы ярдәмендә утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, бәйге комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

20. Бәйге комиссиясе карары кандидат булмаган очракта кабул ителә һәм аны вакант гражданлык хезмәте урынына билгеләү яисә мондый билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып тора. Бәйге комиссиясенең шулай гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә бәйгедә җиңүче булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим итү характерындагы карар кабул итәргә хокукы бар.

21. Бәйге комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре утырышта катнашкан рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган

карар белән рәсмиләштерелә.

22. Бәйге нәтиҗәләре буенча бәйгедә җиңүчене вакант гражданлык хезмәте урынына билгеләү (кадрлар резервына кертү) турында Министрлык боерыгы чыгарыла һәм бәйгедә җиңүче белән хезмәт килешүе төзелә. Әгәр бәйге комиссиясе гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә бәйгедә җиңүче булмаган кандидатны дәүләт органының кадрлар резервына кертү турында карар кабул итсә, күрсәтелгән зат ризалыгы белән гражданлык хезмәтенең вакант урыны караган шул ук төркеменә әлеге органның гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервына кертү турында дәүләт органы акты чыгарыла.

23. Бәйге нәтиҗәләре турында хәбәр ул тәмамланган көннән соң 7 көнлек вакыт эчендә кандидатларга язма рәвештә, шул ук вакытта бәйгедә катнашу өчен документларын электрон рәвештә тапшырган кандидатларга – дәүләт хезмәте өлкәсендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Бәйге нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук вакыт эчендә Министрлыкның рәсми сайтларында һәм әлеге мәгълүмат системасының «Интернет» челтәрендә урнаштырыла.

24. Бәйгедә катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә дәгъва итүчеләрнең һәм бәйгедә катнашучы кандидатларның документлары бәйге тәмамланганнан соң өч ел эчендә язма гариза буенча кире кайтарылырга мөмкин. Бу вакыт тәмамланганчы Документлар дәүләт органы архивында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Бәйгедә катнашу өчен электрон рәвештә тәкъдим ителгән документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

25. Бәйгедә катнашу белән бәйле чыгымнар (бәйге үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынын наймга алу, яшәү, элемтә чараларыннан файдалану һәм башкалар) кандидатларның үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

26. Кандидат бәйге комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары

нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгында
Татарстан Республикасы
дәүләти гражданлык хезмәтенең
вакант урынын биләүгә
(кадрлар резервына кертү) бәйге турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы спорт
министры

___________________________________
кадрлар һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре
буенча сектор мөдире
__________________________________

гариза

Дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә)
бәйге уздыру турында

Сездән ______________________________________________________________________
(бүлек атамасы)
____________________________________________________дәүләт гражданлык хезмәтенең
(вазыйфа атамасы)

вакант урынын биләүгә бәйге игълан итүегезне сорыйм. Әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга түбәндәге квалификацион таләпләр куела:
_________________________________________________________________________________

Кушымта: гражданлык хезмәте вакант урынының вазыйфаи регламенты күчермәсе.

Били торган вазыйфа (имза)
Занимаемая должность (подпись)

"__" __________ 20____ ел